**Д.Х.Хөснетдинов**

**Казан (Идел буе) федераль университеты, Казан**

# “ҖИР” КОНЦЕПТЫНЫҢ ТАТАР ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ БИРЕЛЕШЕ

*(Тикшеренүләр* № 11-14-16029а/В *(РГНФ) номерлы грант кысаларында башкарылды)*

Төрки-татарларда мәкаль-әйтемнәрне бастырып чыгару, аңлатуның меңьеллык тарихы бар. Мәкаль-әйтемнәр төзү һәм таратуда борынгы заманнарда ыру-кабилә башлыклары, халык җырчылары – чичәннәр зур роль уйнаган. Кайбер очракларда мәкаль-әйтемнәр төзелү аерым бер вакыйгалар белән бәйләнгән. Башка халыклардагы кебек үк төрки-татар мәкальләре дә вербаль төстә гади генә хокукларны тасвирлаган һәм аларның үтәлүен таләп иткән. *Җир* лексемасы урын алган мәкаль-әйтемнәрдә бу аеруча ачык чагылыш таба, чөнки ата-бабаларыбызның тормышы, тарихы борын-борыннан җир, дала белән бәйле булган. Шуңа күрә дә халкыбызның борынгы мәдәниятенә барып тоташучы мәкаль-әйтемнәрдә *җир* концепты бары тик урын яисә үсемлек үсүче туфрак буларак кына күзалланмый, ә тарихи вакыйгалар, мифик дөнья, мифик затлар белән бергә үреп барыла. Төрки-татар халкы өчен *җир* мәҗүси ышанулар, шулар белән бәйле тәңре-аллалары булган серле бер дөнья да; галәмнең кайчандыр үрдәк барлыкка китергән дигән мифка барып тоташучы бер планетасы-кисәге дә; шул ук вакытта кешеләрне ачлыктан-ялангачлыктан саклап калучы, аларны туендыручы, үзенә сыендыручы яшәү, чәчү-сөрү җире дә; заманында шуның өчен зур-зур дәүләтләр үзара олы сугышлар алып барган милек-байлык та; еракларга киткәч сагындырып искә төшүче, үзәкләрне өзүче туган җир, ата-баба нигезе дә һәм нәрсәдер куяр, урнаштырыр урын да. Гомумән, татар халкы *җир* сүзенә бик киң

мәгънә сала. Һәм мәкаль-әйтемнәрдә бу бик ачык чагылыш таба. Аларны анализлау нәтиҗәсендә, мәкаль-әйтемнәрдә *җир* лексемасы белдергән мәгънәләр берничә ассоциатив-семантик төркемгә берләштерелде. Шулар арасыннан "Җир – милек, мул уңыш чыганагы", "Җир – туган үскән урын, нигез" кебек ассоциатив-семантик төркемнәрнең бик бай булуы күренде. Гади халык җиргә, беренче чиратта, мул уңыш үстереп, гаиләсен туендыру, яшәү чыганагы дип караган, чөнки ул заманда җире булмаган кеше хәерче булып саналган, җан асрауның башка чыганагы булмаган, бары тик байларга ялланып көн күрергә генә калган. Ә байлар, хакимнәр җирне чын мәгънәсендә милек, байлык дип кабул иткән. Тарихи чыганаклардан күренгәнчә, җирләре күбрәк булган саен ул хаким баерак булып саналган. Ә инде олы дәүләтләр, илләр дәвере килгәч, җир ил байлыгы, халык байлыгы, уртак байлык буларак санала башлый. Шуңа бәйле рәвештә *Җир – халык байлыгы, Җир булмаса, ил дә юк* кебек мәкальләр туа.

Ә күпләр өчен җир туган үскән нигез буларак кабул ителә. Борынгы чорларда патшага хезмәткә яисә сугышларга киткәндә ир-егетләр туган нигезләреннән үзләре белән бер уч туфрак ала торган булганнар. Бу туфрак, бер яктан, алар өчен туган як, туган нигез истәлеге булса, икенче яктан, халыкта шушы туфрак ир-егетләрне туган якларына исән-имин алып кайтарачак дигән ышану да яшәгән. Гомумән, туган нигез, аңа булган мәхәббәт, җылы хисләр иң битараф кеше күңеленең бер почмагында яшерен генә сакланырга, аны үзенә тартып торырга мөмкин. Шуңа күрә дә татар халкы өчен җир күп очракта туган үскән нигезе, туган ягы буларак ассоциацияләнә.

Шунысы игътибарга лаек: *җир* концептын әлеге лексеманың контексттагы бирелешен, үзенчәлекләрен ачыкламый гына бөтен

тулылыгы белән ачып салу мөмкин түгел. Контекстта *җир* лексемасы, нигездә, ия, тәмамлык, урын хәле һәм сирәк кенә хәбәр функцияләрен башкара.

Гомумән, *җир* концептының мәкаль-әйтемнәрдәге чагылышы ерак чорларга барып тоташа. *Җир* концепты халыкның күп гасырлык тормыш тәҗрибәсен гомумиләштерә, кешенең гамәлләрен, тормышка карашларын, вакыйгаларны эмоциональ-экспрессив яктан бәяләүдә дә катнаша.

Әдәбият


1.Исәнбәт Н. Татар халык мәкаль-әйтемнәре. – II том / Н.Исәнбәт. – Казан, 1963. – 1026 б.

2.Исәнбәт Н. Татар халык мәкаль-әйтемнәре. – III том Н.Исәнбәт. – Казан, 1967. – 1015 б.

3.Татар халык иҗаты: Мәкальләр һәм әйтемнәр. – Казан, 1987. – 591 б.

4.Татар халык иҗаты: Табышмаклар. – Казан, 1977. – 584 б.